# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
# **КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында «Һөнәрдән керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү экспериментын уздыру нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасында «Һөнәрдән керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү экспериментын уздыру нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе Л.А. Якунин һәм «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге рәисе урынбасары С.В. Карпухин мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында «Һөнәрдән керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү экспериментын уздыру нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген алып баручы физик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар өчен «Һөнәрдән керемгә салым» махсус салым режимының актуальлеген һәм аңа зур ихтыяҗ булуны билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кәсепчеләрнең хокукый статусын һәм кәсепчеләрнең идентификация чаралары белән мәҗбүри маркировкаланырга тиеш булмаган хезмәт продуктлары исемлеген билгеләүче Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына Татарстан Республикасында «Һөнәрдән керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү экспериментын уздыру турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законның хокукый кулланылышын мониторинглауны дәвам итәргә.

5. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә халыкка «Һөнәрдән керемгә салым» махсус салым режимын куллану мөмкинлеге турында, шулай ук үзмәшгуль гражданнарга күрсәтелә торган дәүләт ярдәме чаралары, шул исәптән финанс һәм финанс булмаган

инструментлар, турында гамәлдә булган элемтә телекоммуникация каналлары («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтлары, социаль челтәрләрдәге аккаунтлар) аша мәгълүмат бирү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

6. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә үзмәшгуль гражданнардан «Минем салым» платформасында уздырылган салым түләүчеләрнең һөнәрдән керемгә салымны куллану шартларыннан канәгатьлек дәрәҗәсен бәяләүгә һәм оптимальләштерүне таләп итә торган параметрларны ачыклауга юнәлдерелгән сораштыру нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН / БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ / ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 20 ноябре
№ 130-VII ДСП